**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 декабрь № 966

г. Казань

Зеленодольск муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенең Зеленодольск муниципаль районында урнашкан, 0,0128 гектар гомуми мәйданлы, шулардан 0,001 гектар – З.Х.Дзюбенко милкендә, 0,001 гектар – А.Г.Талипов милкендә, 0,001 гектар – М.А.Нигъмәтуллин милкендә, 0,001 гектар – Г.Ш.Абдуллина милкендә, 0,0088 гектар дәүләт милкендә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә, энергетика объектлары урнаштыру максатларында, сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:20:160501:35 | 0,001 |
| 16:20:160501:38 | 0,001 |
| 16:20:160502:120 | 0,001 |
| 16:20:160502:122 | 0,001 |
| 16:20:160502:124 | 0,0088 |
| Барлыгы | 0,0128. |

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт ка-

дастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\966.docx